Республика Татарстан

СОВЕТ РАНГАЗАРСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ САРМАНОВСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

ул. Советская, д. 48, с.Рангазар
423377
Телефон: 4-36-54

Татарстан Республикасы

САРМАН МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ РАНГАЗАР АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ

Рангазар авылы, Совет урамы, 48йорты,
423377
Телефон: 4-36-54

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

« 15 » декабрь 2020 ел № 18

Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Рангазар авыл җирлеге Советының 2018 нче елның 27 нче апрелендә кабул ителгән 4 нче номерлы «Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Рангазар авыл җирлегенең сайланган вазыйфаи затына хезмәт өчен түләү нигезләмәсен раслау турында» гы карарына үзгәрешләр кертү турында»

«Татарстан Республикасында муниципаль берәмлекнең вәкиллекле органы депутаты, җирле үзидарәнең сайланулы органы әгъзасы, җирле үзидарәнең сайланулы вазыйфаи заты вәкаләтләрен гамәлгә ашыру гарантияләре турында» 12.02.2009 елдагы 15-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы нигезендә Рангазар авыл җирлеге Советы КАРАР ИТТЕ:

1. Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Рангазар авыл җирлеге Советының 2018 нче елның 27 нче апрелендә кабул ителгән 4 нче номерлы «Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Рангазар авыл җирлегенең сайланулы вазыйфаи затына хезмәт өчен түләү нигезләмәсен раслау турында» гы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) «Сарман муниципаль районы «Рангазар авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең сайланулы вазыйфаи затына хезмәт өчен түләү турында Нигезләмә» нең 1 нче кушымтасын түбәндәге эчтәлекле 6, 7, 8 пунктлар өстәргә:

«6. Муниципаль вазыйфаны даими нигездә биләгән затның еллык түләүле отпускы төп түләүле отпусктан һәм өстәмә түләүле отпусктан тора.

7. Муниципаль вазыйфаларны даими нигездә биләгән затлар өчен ел саен түләнә торган төп түләүле ялның озынлыгы муниципаль хокукый актлар белән билгеләнә, ләкин 30 календарь көннән дә ким булмаска тиеш.

8. Муниципаль вазыйфаны даими нигездә биләгән затка тиешле еллар эшләгән өчен еллык өстәмә түләүле отпуск дәвамлылыгы муниципаль вазыйфа,

муниципаль хезмәт вазыйфасы, шулай ук дәүләт вазыйфасы һәм дәүләт граждан хезмәте вазыйфасы ел саен бер календарь көн исәбеннән исәпләнә. Ел саен бирелә торган төп түләүле отпуск һәм тиешле еллар эшләгән өчен ел саен өстәмә түләүле отпускның гомуми озынлыгы 45 календарь көненнән дә артмаска тиеш».

2. Әлеге карарны "Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында" (PRAVO.TATARSTAN.RU), Сарман муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемә алам.

Сарман муниципаль районы
Рангазар авыл җирлеге
Советы Рәисе А.Р.Шарипова